**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

21.05.2026 № 186

**Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм аларны террорчылыктан саклау мәнфәгатьләрендә категорияләнергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлеген төзергә һәм расларга вәкаләтле орган турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләр һәм сәүдә объектының (территориясенең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары белән расланган сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең 5 пункты нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм аларны террорчылыктан саклау мәнфәгатьләрендә категорияләнергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлеген төзергә һәм расларга вәкаләтле республика башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең актларын әлеге боерыкка туры китерергә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**